| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ МОНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯМЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ |

---

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

26 июль 2024 ел № 126

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципальберәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97- ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2023 елның 03 июлендәге 94 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге»» муниципальберәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 нче статьяның 1.12 нче пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең законлы мәнфәгатьләре хокукларын тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

2. 34 статьяның 1 өлешендәге 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

3. 71 нче статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«71 Статья муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченәкерү тәртибе

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, җирлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә

органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яки
«Менделеевские новости» газетасында бирелгән (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС 77 - 73819 28.09.2018 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор);

2) Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру https://mendeleevsk.tatarstan.ru.

3. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә игълан ителә.

4. Җирлекнең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

6. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарылудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге Җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен игътибарга җиткерелә.».

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге»» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проектына килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемтөзергә:

Мальгин.Г.А. - Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы Рәисе урынбасары;

Семяков С.А.- законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларынсаклау буенча даими комиссия рәисе;

Григорьева Н.С. - Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Башкарма комитетының сәркатибе.

2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге»»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы карары проектына халыктан тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм кабул итүнең түбәндәге тәртибен билгеләргә:

Искәрмәләр, төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр Ф., И., А, туган елы, авторның өй адресы күрсәтелгән язма рәвештә кабул ителә.

Килгән искәрмәләрне, төзәтмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итү һәм исәпкәалуны Менделеевск районы, Монашево авылы, Мәктәб урам, 19 нче йорт адресы буенча эш

төркеме, эш көннәрендә 8: 00дән 16:00гә кадәр башкара.

3. Гамәлдәге законнар нигезендә 2024 елның 9 августында 17.00 сәгатьтә Монашево авылы мәдәният йортында, Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 05 сентябреннән 75 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы карары проекты буенча.

4. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» " муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында” нигезләмәгә ярашлы рәвештә үткәрергә.

5 .Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Монашево авыл җирлеге” бүлегендә урнаштырырга:http://mendeleevsk.tatarstan.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Монашево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф. Иосифов